РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
***Красновидовского сельского Поселения Камско-Устьинского муниципального района***

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Красновидово авыл**
**БАШЛЫГЫ**

С. Красновидово ул. Советская,4
204-13
факс 204-13

**КАРАР**

**2020 елның 16 ноябре** **№3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлегенең Антоновка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авылы җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 2 декабрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Антоновка авылы территориясендә 18 яшькә җиткән, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр гражданнан ,ташламалы категорияләрдән кала (1 төркем инвалидлар, көндезге формада белем алучы студентлар)2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым җыю һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- кышкы юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабып узу (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- контейнер мәйданчыклары төзү (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- контейнерлар сатып алу, шул исәптән зират өчен (контейнерлар сатып алу).

«РИЗА » «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль район, Антоновка ав., Колхоз ур., 9а йорт, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Красновидово
авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге башлыгы И.В.Алешин